БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**

30 июль 2026 ел

**КАРАР**

№66

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының махсуслаштырылган муниципаль торак фондыннан хезмәт торак урыннары бирү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында**

Россия Федерациясе Торак Кодексының 14 статьясындагы 1 өлешнең 4 пункты нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 26 январендагы 42 номерлы карары белән расланган торак урынны махсуслаштырылган торак фондына кертү кагыйдәләренә таянып, Балтач муниципаль район Советы **карар кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының махсуслаштырылган муниципаль торак фондыннан хезмәт торак урыннары бирү Тәртибен кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (http://baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына йөкләргә.

Балтач муниципаль районы
башлыгы урынбасары,
Балтач район Советы рәисе урынбасары

Н.Н. Сабирҗанов

Татарстан Республикасы
Балтач район Советының
2026 елның «30» июлендәге
66 номерлы карарына кушымта

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының махсуслаштырылган муниципаль торак фондында булган хезмәт торак биналарын бирү тәртибе турында Нигезләмә

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Бу Нигезләмә, Россия Федерациясе Торак кодексының 14 нче статьясындагы 1 нче өлешнең 4 нче пунктына туры китереп, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законга нигезләнеп, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 26 январендагы 42 номерлы карары белән расланган махсуслаштырылган торак фондына торак биналарны кертү кагыйдәләренә таянып эшләнгән.

1.2. Торак урынны хезмәт торагы буларак куллану, мондый урынны Россия Федерациясе Торак кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 26 январендагы 42 номерлы карары белән расланган махсус торак фондына тапшыру кагыйдәләре һәм әлеге Нигезләмә белән билгеләнгән таләпләр һәм тәртип нигезендә махсус торак фондына тапшырганнан соң гына, рөхсәт ителә.

Торак урынны махсуслаштырылган торак фондына кертү, мондый урынны махсус төр - хезмәт торагы дип санау, шулай ук торак урынны күрсәтелгән торак фондыннан чыгару Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты боерыгы нигезендә башкарыла.

1.3. Торак урынын махсуслаштырылган торак фондына кертү, күрсәтелгән торак фондыннан чыгару турында карар Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты боерыгы формасында кабул ителә һәм әлеге карарны кабул итү көненнән алып, өч эш көне эчендә Балтач муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына, күчемсез милек һәм аңа бәйле эшләргә хокукларны теркәүне тормышка ашыра торган органга җибәрелә.

1.4. Торак урыннары дәүләт яки муниципаль милектәге торак урынына социаль найм, торак урынына найм, коммерцияле кулланулы торак фондына аренда буенча биләнгән очракта, шулай ук бу мөлкәткә хокук йөкләмәләре булган очракта, торак урыннарын хезмәт торак урыннарына кертү рөхсәт ителми.

1.5. Хезмәт торагы итеп тапшырылган торак урыннары гражданнарның даими яшәве өчен яраклы булырга (санитария, техник кагыйдәләр һәм билгеләнгән нормаларга, янгын куркынычсызлыгы таләпләренә, экология һәм

законлылыкның башка таләпләренә туры килергә), шулай ук тиешле торак пункты шартлары буенча төзекләндерелгән булырга тиеш.

1.6. Махсуслаштырылган торак фондындагы хезмәт торак урыннары Балтач муниципаль районының җирле үзидарә органнары, дәүләт, муниципаль учреждениеләр белән хезмәт мөнәсәбәтләре характерына бәйле рәвештә гражданнарның яшәве өчен билгеләнгән.

1.7. Хезмәт торак урыннары торак йорт һәм аерым фатир рәвешендә тәкъдим ителә.

Берничә торак яллаучы һәм (яисә) торак урын милекчесе яшәгән фатирлардагы бүлмәләрне хезмәт торак урыны буларак бүлеп бирү рөхсәт ителми.

Күпфатирлы йортта хезмәт торак урыны буларак барлык торак урыннар да, аларның бер өлеше дә файдаланылырга мөмкин.

1.8. Торак урыннары тартып алынмый, арендага, вакытлы файдалануга (наемга) бирелми, мондый урыннарны хезмәт торак урыннары буларак вакытлы файдалану (наем) килешүләре буенча тапшыру очракларыннан тыш.

1.9. Хезмәт торак урыннары Балтач муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәбәтләре палатасында исәпкә алынырга тиеш. Балтач муниципаль районы торак фондының хезмәт торак урыннарына мохтаҗ булган гражданнарны исәпкә алу тәртибе Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты тарафыннан билгеләнә.

1.10. Хезмәт торак урыннарының найм килешүләре реестры Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетында алып барыла.

## 2. Хезмәт торак урыннары бирү

2.1. Хезмәт торак урыннары Балтач муниципаль районында эшчәнлек алып барган, торак урыннары булмаган хезмәткәрләргә тәкъдим ителә.

2.2. Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органы, дәүләт, муниципаль учреждение яки предприятие җитәкчесе тарафыннан хезмәткәргә хезмәт торак урыны бирү мәсьәләсен карау өчен, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетына түбәндәгеләр тапшырыла:

1) җитәкченең үтенечнамәсе;

2) гражданинның (алга таба — гариза бирүче) хезмәт торак урыны сорап мөрәҗәгать иткән көнен һәм үз имзасын куеп, гаиләнең барлык балигъ булган әгъзалары тарафыннан имзаланган гаризасы (3 нче кушымта);

3) гражданинның һәм аның гаилә әгъзаларының шәхесен раслаучы документларның күчермәсе (барлык битләр);

4) гариза бирүче һәм гаилә әгъзаларының гаилә составын һәм туганлык мөнәсәбәтләрен раслый торган документлар күчермәсе;

5) торак урынының гомуми һәм торак мәйданы, бирелү вакыты күрсәтелгән финанс-шәхси исәп күчермәсе;

6) гариза бирүче һәм аның гаилә әгъзалары белән бергә торак урыннарында яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар турында белешмәләр булган документлар;

7) торакка хокук билгеле торган документларның күчермәләре (ЕГРН да документлар теркәлмәгән очракта - гариза бирүче тарафыннан тапшырыла);

8) техник инвентаризация органыннан гариза бирүче һәм аның гаилә әгъзаларына карата Татарстан Республикасы территориясендә 2000 елның 1 январеннан элек милектә торак булуы яки аны читләштерү килешүләре турында мәгълүмат;

9) Балтач муниципаль районының җирле үзидарә органнары, муниципаль учреждениеләр белән хезмәт мөнәсәбәтләрен раслый торган документлар.

2.3. Хезмәт торак урыны бирү турында карар Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты боерыгы формасында кабул ителә һәм хезмәт торак урынына найм килешүен төзү өчен нигез булып тора.

Кабул ителгән карар турында мәгълүмат әлеге карарны кабул итү көненнән алып өч эш көне эчендә гариза бирүчегә җибәрелә.

2.4. Хезмәт торак урынын вакытлы файдалану (найм) килешүе Балтач муниципаль районында дәүләт, муниципаль хезмәт үтү буенча хезмәт мөнәсәбәтләре чорына төзелә.

2.5. Хезмәт мөнәсәбәтләре туктатылу, шулай ук дәүләт, муниципаль хезмәттән китү хезмәт торак урынына найм килешүен туктату өчен нигез булып тора.

2.6. Торакны файдалануга алучы һәм аның белән бергә яшәүче гаилә әгъзалары тарафыннан хезмәт торак урынына найм килешүе буенча йөкләмәләр үтәлмәсә, хезмәт торак урынына найм килешүе найм бирүче таләбе буенча суд тәртибендә өзелергә мөмкин, шулай ук Россия Федерациясе Торак кодексында каралган башка очракларда.

Хезмәт торак урынына найм килешүе торак урынын юкка чыгаруга (җимерүгә) бәйле рәвештә яисә Россия Федерациясе Торак кодексында каралган башка нигезләрдә туктатыла.

2.7. Хезмәт торагын арендалау килешүендә торак бирүче булып Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты тора.

2.8. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты хезмәт торак урыннары бирелгән эшчеләрнең эш бирүчеләреннән (юридик затлардан) бу эшчеләр белән хезмәт мөнәсәбәтләре дәвам итү яки туктатылуны раслауны таләп итә ала.

2.9. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетына дәүләт, муниципаль учреждение җитәкчеләре тарафыннан хезмәт торагы бирелгән эшче белән хезмәт мөнәсәбәтләре туктатылу турында 10 көн эчендә язмача хәбәр ителергә тиеш.

2.10. Бер хезмәт торагыннан икенчесенә үз теләге белән күчү, шулай ук хезмәт торагын арендалау килешүенә кертелмәгән затларны урнаштыру рөхсәт ителми.

2.11. Бушаган хезмәт торак урыннары әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә кабат бирелә.

2.12. Хезмәт торак урыннарын арендалау килешүләре өзелгән яки туктатылган очракта гражданнар һәм аның белән бергә яшәүче гаилә әгъзалары биләгән торак урыннарын бушатырга тиеш. Әгәр дә бу торак урыннарын

бушатудан баш тартсалар, әлеге гражданнар суд тәртибендә чыгарыла, башка торак урыннары бирелми, Россия Федерациясе Торак кодексында каралган очраклардан тыш.

2.13. Россия Федерациясе Торак кодексының 2.6 статьясының 2 нче пунктында күрсәтелгән категорияле гражданнар башка торак урыннары бирелмичә хезмәт торак урыныннан чыгарыла алмый.

3. Хезмәт торагына найм килешүе буенча хезмәт торагын файдалану.

Хезмәт торагын вакытлы файдаланучының һәм аның гаилә әгъзаларының, шулай ук вакытлы файдалануга бирүченең хокук һәм бурычлары Балтач муниципаль районының махсус торак фондындагы хезмәт торак урынына найм килешүе белән регламентлана.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районының
махсуслаштырылган муниципаль торак
фондының хезмәт торак урыннары бирү
тәртибе турындагы Нигезләмәгә
1 нче кушымта

Балтач муниципаль районының махсуслаштырылган муниципаль торак фондында хезмәт торак урыннары бирелергә мөмкин булган гражданнар категорияләре исемлеге

Хезмәт торак урыннары түбәндәге гражданнар категорияләренә бирелә:

1. Балтач муниципаль районының җирле үзидарә органнарындагы муниципаль вазыйфаларны һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затлар.

2. Балтач муниципаль районының муниципаль учреждение һәм муниципаль предприятие хезмәткәрләре.

3. Балтач муниципаль районының җирле үзидарә органнарына, муниципаль учреждение һәм муниципаль предприятиеләргә эшкә чакырылган белгечләр.

4. Балтач муниципаль районы территориясендә эшләүче Россия Федерациясе дәүләт органнары һәм дәүләт учреждениеләре җитәкчеләре һәм белгечләре.

5. Хәрби хезмәткәрләр, шулай ук Балтач муниципаль районының иминлеген һәм тормыш эшчәнлеген тәэмин итүче башка категория хезмәткәрләр.

6. Балтач муниципаль районында урнашкан территориаль дәүләт органнарына, районның җирле үзидарә органнарының сайланулы вазыйфаларына сайлану нәтиҗәсендә вазыйфаи затларга.

7. Балтач муниципаль районында хезмәт куючы хокук саклау органнары хезмәткәрләренә.

8. Балтач муниципаль районының медицина учреждениеләрендә профессиональ эшчәнлек алып баручы табиб, шәфкать туташы һәм башка медицина хезмәткәрләренә.

9. Балтач муниципаль районының башка бюджет предприятиеләре һәм учреждениеләре хезмәткәрләренә.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районының
махсуслаштырылган муниципаль торак
фондының хезмәт торак урыннары бирү
тәртибе турындагы Нигезләмәгә
2 нче кушымта

Хезмәт торак урынына наймның
______________________номерлы
ТИПОВОЙ ШАРТНАМӘСЕ

________________________________________ ____________________
(торак пункт атамасы) (көн, ай, ел)

__________________________________________________________________
(хезмәт торак урыны хуҗасының исеме яки
__________________________________________________________________
аның исеменнән эш итүче дәүләт хакимиятенең вәкаләтле органы
__________________________________________________________________
Россия Федерациясе, дәүләт хакимияте органы
__________________________________________________________________
Россия Федерациясе субъекты, җирле үзидарә органы
__________________________________________________________________
яки алар тарафыннан вәкаләт бирелгән башка зат,
__________________________________________________________________,
вәкаләт бирүче документның исеме, аның датасы һәм номеры)
алга таба Найм бирүче дип аталучы, бер яктан, һәм
гражданин(ка)
_______________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)
__________________________________________________________________,
алга таба торак яллаучы дип аталучы, икенче яктан, торак урын бирү турында 20__ елның «____» ____________________ ____номерлы карар нигезендә әлеге Шартнамәне төзеделәр.

## I. Шартнамә Предметы

1. Наем бирүче Яллаучыга һәм аның гаилә әгъзаларына түләүле итеп файдалануга, __________________________________________да булган
__________________________________________________________________
(дәүләт, муниципаль - кирәклесен күрсәтергә)
дәүләт теркәве турында 20__елның «____» _____________ _____номерлы Таныклык нигезендә, гомуми мәйданы _______________ кв. метр

булган квартирадан торган, __________, й. __, корп. ____, кв. __ урнашкан торак урынны анда вакытлыча яшәү өчен тапшыра.

2. Торак урыны

______________________________________________________________

(эш, хезмәт узу, Россия Федерациясе дәүләт вазыйфасына

______________________________________________________________

______________________________________________________________________

__________ Россия Федерациясе субъектының дәүләт вазыйфасы яки сайланулы вазыйфага билгеләнү ___________________

____________________________________ белән бәйле рәвештә бирелә кирәклесен күрсәтергә)

3. Бирелә торган торак урынның характеристикасы, аның техник хәле, шулай ук аның эчендә урнашкан санитар-техник һәм башка җиһазлары торак урынның техник паспортында күрсәтелгән.

4. Файдалануга алучы белән бергә торак урынга аның гаилә әгъзалары кертеләләр:

1) __________________________________________________________;
(Файдалануга алучының гаилә әгъзасының фамилиясе, исеме, атасының исеме һәм аның белән туганлык дәрәҗәсе)

2) __________________________________________________________;
(Файдалануга алучының гаилә әгъзасының фамилиясе, исеме, атасының исеме һәм аның белән туганлык дәрәҗәсе)

3) __________________________________________________________.
(Файдалануга алучының гаилә әгъзасының фамилиясе, исеме, атасының исеме һәм аның белән туганлык дәрәҗәсе)

5. Әлеге Шартнамә

______________________________________________________________

(хезмәт мөнәсәбәтләре, хезмәт узу, Россия Федерациясе дәүләт вазыйфасында булу_______________________________________
Россия Федерациясе субъекты вазыйфасы яки сайланулы вазыйфада)

______________________________________________________________________

_____________ вакытына төзелә.

## II. Файдалануга алучының һәм аның гаилә әгъзаларының хокук һәм бурычлары

6. Файдалануга алучы түбәндәге хокукларга ия:

1) яшәү өчен торак урынын куллану, шул исәптән гаилә әгъзалары белән яшәү;

2) күпфатирлы йортта уртак милектән файдалану;

3) торакның кагылгысызлыгы һәм торак урыннан теләсә кайчан мәхрүм итүгә юл куймау. Законлы нигездә анда яшәүче гражданнарның ризалыгыннан башка, федераль законда күздә тотылган тәртиптә һәм очраклардан тыш яки суд карары нигезеннән башка, хезмәт торак урынына беркем дә керергә хокуклы түгел. Хезмәт торак урынында законлы нигездә яшәүче гражданнар бу

торактан куып чыгарыла яки файдалану хокукында чикләнә алмый, бары тик Россия Федерациясе Торак кодексында һәм башка федераль законнарда күздә тотылган тәртиптә һәм нигезләр буенча гына;

4) әлеге Шартнамәне теләсә кайсы вакытта өзү;

5) торак урынның яңа хуҗасы яки мондый торак урын тапшырылган юридик зат эшче - файдаланучы алучы белән хезмәт килешүендәге бер як (сторона) булган очракта, бу урынга милек хокукы, шулай ук хуҗалык алып бару яки оператив идарә итү хокукы күчкәндә, хезмәт торак урыныннан файдалану хокукын саклап калу;

6) Россия Федерациясе Торак кодексының 159 статьясында билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр алу.

Файдаланучы алучы законнарда каралган башка хокукларга ия булырга мөмкин.

7. Файдаланучы алучы түбәндәгеләргә бурычлы:

1) торак урынын Россия Федерациясе Торак кодексында билгеләнгән кысаларда һәм билгеләнеш буенча куллану;

2) торак урыннан файдалану кагыйдәләрен үтәү;

3) торак урынның сакланышын тәэмин итү;

4) торак урынны тиешле хәлдә тоту. Үз белдеге белән үзгәртү яки яңадан планлаштыру рөхсәт ителми;

5) торак урынга агымдагы ремонт ясау;

6) торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен вакытында түләү (мәҗбүри түләүләр) кертү. Торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү кертү йөкләмәсе әлеге Шартнамә төзелгәннән соң башлана. Торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен вакытында түләмәү Россия Федерациясе Торак кодексының 155 статьясында билгеләнгән тәртиптә һәм күләмдә пенялар алынуга китерә;

7) капиталь ремонт вакытында гаилә әгъзалары белән Наемга бирүче тарафыннан тәкъдим ителгән башка торак урынына күчү (ремонтны күченмичә башкара алмаганда). Файдаланучы алучы һәм аның гаилә әгъзалары бу торак урынына күченүдән баш тарткан очракта, Наемга бирүче суд тәртибендә күченүне таләп итә ала;

8) торак урынның санитар-техник, техник торышын һәм андагы башка җиһазларны карау, шулай ук кирәкле эшләрне башкару өчен алдан килештерелгән вакытта Наемга бирүченең вәкилен торак урынга кертү;

9) торак урынының яисә андагы санитар-техник һәм башка җиһазларның төзексезлеге ачыкланганда, кичекмәстән аларны бетерү өчен мөмкин булган чаралар күрергә һәм кирәк булган очракта алар турында Наемга бирүчегә яки тиешле эксплуатацияләүче яки идарәче оешмага хәбәр итү;

10) торак урыннан файдалануны күршеләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен саклап, янгын куркынычсызлыгы таләпләрен, санитар-гигиена, экология һәм законнарның башка таләпләрен исәпкә алып гамәлгә ашыру;

11) торак урынны бушатканда аны 3 көн эчендә Наемга бирүчегә тиешле хәлдә тапшыру, үзенең бурычы булып та башкарылмаган торак урынны

агымдагы ремонтлау бәясен түләү, шулай ук торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен бурычны каплау;

12) әлеге Шартнамәне өзү яки туктату вакытында торак урынны бушату. Торак урынны бушатудан баш тарткан очракта, торакны яллаучы һәм аның гаилә әгъзалары суд тәртибендә чыгарылырга тиеш.

Торакны яллаучы законнарда каралган башка йөкләмәләрне үти.

8. Торакны яллаучы һәм аның гаилә әгъзаларының вакытлыча булмавы аларның әлеге Шартнамә буенча хокукларын һәм йөкләмәләрен үзгәртми.

9. Торакны яллаучының торак урынны алмаштырырга, шулай ук аны наемга тапшырырга хокукы юк.

10. Торакны яллаучының гаилә әгъзалары торакны яллаучы белән торак урыннан куллану буенча тигез хокуклы, әгәр торакны яллаучы һәм аның гаилә әгъзалары арасындагы килешүдә башкача билгеләнмәгән булса.

11. Торакны яллаучының гаилә әгъзалары хезмәт торак урынын билгеләнеш буенча кулланырга һәм аның саклanышын тәэмин итәргә бурычлы.

12. Торак урыннан куллану барышында килеп чыккан йөкләмәләр буенча торакны яллаучының юридик хокуклы гаилә әгъзалары торакны яллаучы белән бертигез җаваплы, әгәр торакны яллаучы белән аның гаилә әгъзалары арасындагы килешүдә башкача билгеләнмәгән булса. Торакны яллаучы белән гаилә мөнәсәбәтләре тукталган очракта, элекке гаилә әгъзалары өчен торак урыннан куллану хокукы сакланмый, әгәр торакны яллаучы белән элекке гаилә әгъзалары арасындагы килешүдә башкача билгеләнмәгән булса.

## III. Наемга бирүченең хокук һәм бурычлары

13. Наемга бирүче түбәндәгеләргә хокуклы:

1) торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүне вакытында кертүне таләп итәргә;

2) торакны яллаучы тарафыннан торак законнары һәм әлеге Шартнамәнең шартлары бозылган очракта, әлеге Шартнамәне өзүне таләп итәргә;

3) торак урынны хосусыйлаштыру турында карар кабул итәргә.

Наемга бирүче законнарда каралган башка хокукларга ия булырга мөмкин.

14. Наемга бирүче түбәндәгеләргә бурычлы:

1) торак яллаучыга башка затларның хокукларыннан азат булган һәм яшәү өчен яраклы торак урынны янгын куркынычсызлыгы, санитария-гигиена, экология һәм башка таләпләргә җавап бирә торган халәттә тапшырырга;

2) торак урнашкан күпфатирлы йортта гомуми милекне тиешенчә тотуда һәм ремонтлауда катнашырга;

3) торак урынга капиталь ремонт ясарга;

4) капиталь ремонт яки реконструкция вакытында (ремонт яки реконструкция торак яллаучыны күчермичә эшләнә алмаганда) торак яллаучыга һәм аның гаилә әгъзаларына, әлеге Шартнамәне өзмичә, маневр фондының торак урынын (1 кешегә ким дигәндә 6 кв. м. яши торган мәйданнан исәпләп) тәкъдим итәргә. Торакны яллаучы һәм аның гаилә әгъзаларын маневр

фондының торак урынына күчерү һәм кире күчерү (капиталь ремонт яки реконструкция тәмамлангач) Наемга бирүче акчасына башкарыла.

5) йортны капиталь ремонтлау яки реконструкцияләү эшләре башланырга 30 көннән дә соңга калмыйча торакны яллаучыга хәбәр итәргә;

6) торак йортны, андагы санитар-техник һәм башка җиһазларны кышкы шартларда файдалануга үз вакытында әзерләүдә катнашырга;

7) Наемга алучыга коммуналь хезмәтләр күрсәтүне тәэмин итәргә;

8) әлеге Килешүдә билгеләнгән срокларда, әлеге килешүнең 7 пунктындагы 11 пунктчасында каралган шартларны үтәп, торакны яллаучыдан торак урынын кабул итеп алырга;

9) торак урынын үзгәртеп кору һәм яңадан планлаштыру вакытында Россия Федерациясе Торак кодексында билгеләнгән таләпләрне үтәргә;

10) әлеге Килешүне өзү белән бәйле рәвештә, Россия Федерациясе Торак кодексының 103 нче статьясына ярашлы, бүтән торак урыны бирелүгә хокукы булган гражданнарга бүтән торак урыннар тәкъдим итәргә;

Наемга бирүче законнарда каралган башка йөкләмәләрне үти.

## IV. Шартнамәне өзү һәм туктату

15. Торак яллаучы әлеге Шартнамәне теләсә кайсы вакытта өзәргә мөмкин.

16. Әлеге килешү яклар килешүе буенча теләсә кайсы вакытта өзелергә мөмкин.

17. Әлеге Шартнамәне, Наемга бирүче таләбе буенча, суд тәртибендә өзү түбәндәге очракларда рөхсәт ителә:

1) Торак яллаучының торак урыны һәм (яки) коммуналь хезмәтләр өчен 6 айдан артык түләмәве;

2) Торак яллаучы яисә аның гаилә әгъзалары тарафыннан торак урынны җимерү яисә зарарлау;

3) күршеләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен системалы рәвештә бозу;

4) торак урынын билгеләнеше буенча файдаланмау.

18. Әлеге килешү түбәндәге очракларда туктатыла:

1) торак урынны югалту (җимерү);

2) торак яллаучының вафат булуы;

3) хезмәт килешүе срогы тәмамлану;

4) хезмәт вакыты тәмамлану;

5) Россия Федерациясе дәүләт вазыйфасында, Россия Федерациясе субъекты дәүләт вазыйфасында яки сайланулы вазыйфада булу срогы тәмамлану.

19. Хезмәт килешүе срогы тәмамлану, хезмәт вакыты тәмамлану, Россия Федерациясе дәүләт, муниципаль яки сайланулы вазыйфада булу срогы тәмамлануга бәйле рәвештә әлеге Килешүне өзү яки туктату очрагында торак яллаучы һәм аның гаилә әгъзалары торак урынны бушатырга тиеш. Торак урынны бушатудан баш тарткан гражданнарны, башка торак урын бирмичә

тpraктан чыгарырга, Россия Федерациясе Торак кодексында каралган очраклардан тыш.

## V. Шартнамә буенча түләү кертү

20. Торак яллаучы торак урыны өчен түләүне Россия Федерациясе Торак кодексында каралган тәртиптә һәм күләмдә кертә.

## VI. Башка шартлар

21. Әлеге килешү буенча яклар арасында барлыкка килергә мөмкин булган бәхәсләр законнарда каралган тәртиптә хәл ителә.

22. Әлеге Шартнамә 2 нөсхәдә төзелә, берсе Наемга бирүчегә, икенчесе торак яллаучыга.

Наемга бирүче__________ (имза)

Торакны файдалануга алучы ___________ (имза)

Мөһер урыны

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районының
махсуслаштырылган муниципаль торак
фондының хезмәт торак урыннары бирү
тәртибе турындагы Нигезләмәгә
3 нче кушымта

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе
_________________________________________
(Ф.И.А.)
Гражданин ____________________________
(Ф.И.А. тулысынча)

__________________________________________
_______________ адресы буенча теркәлгән
(почта индексы, тулы адрес)
__________________________________________
(контактлы телефон)

ГАРИЗА

____________________________________________________ бәйле рәвештә
(Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы махсуслаштырылган торак фондындагы торак урыннарын бирү сәбәпләрен күрсәтергә)

миңа һәм ______кешедән торган гаиләмә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының махсуслаштырылган торак фондыннан хезмәт торак урынын найм килешүе буенча бирүегезне сорыйм.

Мин һәм минем гаилә әгъзалары «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясы нигезендә минем шәхси мәгълүматларымны автоматлаштырылган, шулай ук автоматлаштыру чараларын кулланмыйча эшкәртүгә, атап әйткәндә, «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 3 пунктында каралган гамәлләрне башкаруга ризалык бирәбез.

Әлеге ризалык күрсәтелгән мәгълүматлар булган тиешле мәгълүматны яки документларны саклауның Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнгән вакыты чыкканчы бирелә.

Мөрәҗәгать итүче ______________

(Ф.И.А. тулысынча) (имза)

Гаиләнең юридик хокуклы әгъзалары:

1.

2.

3.

4.

(Ф.И.А. һәм гаиләнең юридик хокуклы барлык әгъзаларының имзалары)